СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

21.03.2022 № 19/9
На №__________ от______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 28 маендагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм шәхси торак төзелеше өчен гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен билгеләү турында» 11/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Җирләрдән оптималь файдалану һәм артык ваклануын булдырмау, гражданнарны җир кишәрлекләре белән тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексына, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 мартындагы 112-ФЗ номерлы Федераль законга, муниципаль берәмлек уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 28 маендагы 11/3 номерлы карарына түбәндәге редакциядәге 6.1 пунктын өстәргә:

«Иң чик күләмнәргә карата искәрмә булып иң чик минималь күләмнән ким булган (әмма 600 кв. метрдан да ким түгел), чикләрне яңадан бүлү нәтиҗәсендә яки берничә җир кишәрлеген берләштерү юлы белән төзелә торган, әгәр аларның контурлары чиктәш җир кишәрлекләре яки шәһәр төзелешен җайга салу линияләре (кызыл линияләр, территорияләрдән махсус файдалану зоналары һ.б.) белән чикләнгән очракта, җир кишәрлекләре тора, болар нигезендә 1000 кв. м җир кишәрлеген төзү мөмкин түгел.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М.Камаев